**Куанып хозурда йөргәндә,**
**Карурман куенына кергәндә,**
**Беркемнең каргышын алма син,**
**Күбәләк тә елап калмасын...**
**Сак бул син, сабыем, сак бул син,**
**Саклый күр табигать баласын.**
**Онытма, туган җир бер генә,**
**Кадерләрен аның бел генә...**
**Дәвала аның һәр ярасын,**
**Син бит соң табигать баласы! ( Р. Вәлиева).**







**Наш адрес:**
**РТ, Тюлячинский район**
**Деревня Верхние Кибя-Кози**
**ул. Ленина, 1.**
**Телефон: 56-5-13**
**E-mail: vkibiakozi@mail.ru**



# Экологик әхлак кагыйдәләре



*2014 ел*

# Кагыйдәләр

1. Әйләнә-тирә мөһитне пычратмаска
2. Табигатькә сакчыл караш булдырырга
3. Табигать  өчен уңай эшләр башкарырга.
4. Әйләнә-тирә мөхит турында кайгыртырга.
5. Эш гамәлләрегезнең нәтиҗәсен  алдан күрергә өйрәнергә.
6. Исеңдә тот! Син табигатьтәге хзгәрешләр өчен җаваплы
7. Табигатьтә бер тереклек иясенә дә зыян салма.
8. Бар тереклек иясенә ярдәм ит!

# Уйланыгыз!

1. Казан шәһәрендә ел саен 300 мең тонна чүп җыела
2. Иделдә 100 мең куб метр су биологик чистартуларсыз ташлна.
3. Ташланган кәгазь-2, калай банкалар-90, полиэтилен пакетлар-200, пыяла 1000 елдан соң таркала.
4. Җиңел машина 1000 км юл үткәндә, кешегә 1 ел буена җитәрлек кислород сарыф ителә.
5. Республикада һәр кеше 1 елга 200 кг. Зарарлы матдә “йота”

## Табышмаклар

**Өй башына утырган,**
**Җир йөзен нуры белән тутыр-**
**ган.**
(Кояш*)*

**Ялт-йолт ялтырый,**
**Җирнең өсте калтырый,**
**Энҗе кебек тезелә,**
**Ефәк кебек сузыла.**
***(****Яшен, яңгыр)*

**Аты юк, тәртәсе юк,**
**Көне-төне бара, юлы кала.**
*(Елга, чишмә)*

**Яз килсә – киенә,**
**Көз килсә – чишенә.**
(Агач)

**Бер кошым бар: тынмый,**
**Агачка оя кормый;**
**Ое-җирдә,**
**Җыры – күктә.**
(Тургай)

**Ала-сыер ятып кала,**
**Ак сыер торып китә.**
***(****Яз)*